Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-6**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милкеннән мөлкәтне “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә тапшыру турында

Муниципаль милекне оптималь файдалану максатларында һәм 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 51 маддәсенең 2 өлешенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 июнендәге “ Мөлкәтне федераль милектән Россия Федерациясе субъекты милкенә яки муниципаль милеккә, Россия Федерациясе субъекты милкеннән федераль милеккә яки муниципаль милеккә, муниципаль милектән федераль милеккә яки Россия Федерациясе субъекты милкенә тапшыру турында карар кабул итү өчен зарури документлар исемлекләре турында” 374 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтага ярашлы рәвештә муниципаль мөлкәтне “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкеннән “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкенә тапшырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2019 елның 24 сентябрендәге
XLV-6 номерлы карарына
кушымта

“Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы”
муниципаль берәмлеге милкенә тапшырыла торган мөлкәт
исемлеге

| № п\п | Инвентарь яки кадастр номеры | Объектның исеме һәм сыйфатламасы | Булу урыны (адрес) | Саны, данә | Кертелү (эшләнү) елы | Баштагы торгызу бәясе, сум | Тузу | | Калган бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | % | сум | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | 08110134012245 | Пехота хәрби машинасы БМП-1П (завод номеры В07ЖТ1874), башня номеры В07ЖТ5252, корпус номеры В07ЖТ5306, пушка Д975 | 422980, РТ, Чистай шәһәре | 1 | 01.01.1979 | 1 330 000,00 | 100 | 1 330 000,00 | 0,00 |